БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 17 » апрель 2018 ел № 122

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы
муниципаль белем бирү учреждениеләре җитәкчеләрен
аттестацияләүне үткәрү тәртибе турында

Әлеге вазыйфаларны биләүгә дәгъва итүче җитәкчеләрнең һәм затларның квалификация дәрәҗәләренең аларның һөнәри эшчәнлекләрен бәяләү нигезендә квалификация характеристикаларына туры китереп, аларның вазыйфаларына куела торган таләпләргә туры килүен билгеләү максатыннан, "Россия Федерациясендә мәгариф турында" 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 51 статьясындагы 4 өлеше, "Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы оешмалары җитәкчеләрен (директорларын, мөдирләрен) аттестацияләү тәртибе турында якынча нигезләмәне раслау хакында" 2014 елның 10 ноябрендәге 6347/14 номерлы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы, "Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контроль департаментының планлы тикшерү графигы буенча 2010 нчы елның 10 нчы ноябреннән 6347/14 нче номерлы боерыгы, "Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы оешмалары җитәкчеләрен (директорларын, мөдирләрен) аттестацияләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында" 2017 елның 19 апрелендәге 3822/17 номерлы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы хаты, "Процедураларны оптимизацияләү турында" 2018 елның 22 мартындагы 2645/18 номерлы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы хаты нигезендә, Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль белем бирү учреждениеләре җитәкчеләрен аттестацияләүне үткәрү тәртибе турында нигезләмәне 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль белем бирү учреждениеләре җитәкчеләрен аттестацияләүне үткәрү комиссиясе составын 2 нче кушымта нигезендә расларга .

3. "Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе" МКУн Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль белем бирү учреждениеләре җитәкчеләрен аттестацияләүне гамәлгә ашырырга вәкаләтле орган итеп билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе                                                                 Р. И. Шакиров